КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 сентябрь г.Казань № 842

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасы Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)». 3 нче этап – 89+641 км– 145+143 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск – Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын урнаштыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегенең 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы, 2022 елның 11 гыйнварындагы КС-17/98 номерлы концессион килешү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 декабрь, 2668-б номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 08 декабрь, 2800-б номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Автострада» акционерлык җәмгыятенең Татарстан Республикасының Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) - Баулы (М-5)». 3 нче этап - 89+641 км - 145+143 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск - Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын урнаштыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Карамыш авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, гражданнар Ф.Х.Юнусованың (1/2 өлеш) һәм И.Н.Юнусовның (1/2 өлеш) (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчеләре) өлешле милкендә булган, 140 572 кв.метр мәйданлы,

16:41:000000:2181 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килгән 1436 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районындагы Карамыш авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчеләренә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, «Автострада» акционерлык җәмгыятенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчеләренә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчеләре тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

3. «Автострада» акционерлык җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)». 3 нче этап – 89+641 км – 145+143 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск – Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын урнаштыру карала торган территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын раслау турында» 2022 ел, 25 ноябрь, 1262 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә 16:41:000000:2181 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләү күләмен билгеләүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин